■ Иман

"Һәр бинаның нигезе бар. Исламның нигезе - күркәм әхлак".
Ибн Габбас.

# ӘХЛАК

Габдрахман КАЙА

*Дауамы. Башы 2-че номерда.*

### ГАИЛӘБЕЗГӘ КАРАТА БУЛГАН ВАЗИФАЛАРЫБЫЗ

Һәр җәмгыятьнең яисә милләтнең иң кечкенә кисәге - гаиләдер. Гаиләнең нигезе ана-ата белән төзелер. Гаилә эчендә яшәүче кешеләрнең бер-берләренә карата булган вазифалары да бар. Боларны өч өлешкә аерып карарга мөмкин:

- ата-ананың балаларына карата булган вазифалары;
- балаларның ата-аналарына карата булган вазифалары;
- туганнар һәм кардәшләрнең бер-берләренә карата булган вазифалары.

### АТА-АНАНЫҢ БАЛАЛАРЫНА КАРАТА БУЛГАН ВАЗИФАЛАРЫ

Ата-ананың вазифасы бала тудыру белән генә чикләнми. Туган баланы сәламәт итеп үстерү, яхшы тәрбияләү, дине вә милләте өчен файдалы кылу - ата-ананың иң зур вазифаларыннан исәпләнә. Пәйгамбәребез бер хәдисендә түбәндәгечә боерган: "Балаларыгызны яхшы багыгыз. Аларны яхшы тәрбия кылыгыз".

Ата-ананың баласына карата булган вазифалары нигездә түбәндәгеләр:

-ата-ана баласы хәләл ризыклар белән тукландырыр;
- бала тугач, дини гадәтләр буенча матур вә мәгънәле исем кушар;
- ир баласын сөннәтле иттерер;
- мәктәп яшенә җиткәч, аны мәктәпкә җибәрер, укыта башлар;
- җиде яшеннән әкрен, генә дини белемнәрне өйрәтер һәм вак сүрәләрне ятлатыр;
- ун яшенә җиткәч, намаз укырга өндәр. Бу яшьтән соң балага "Коръән" укырга һәм динебезнең нигезләрен өйрәтү - ата-ананың иң мөһим вазифаларыннан санала;
- ата-ана балалары арасында аерма ясамас;

Исламияткә кадәр булган чорда гарәпләр кыз балаларын яратмаганнар, аларны тереләй җиргә күмә торган булганнар. Исламият мондый эшләрне катгый рәвештә тыйды. Пәйгамбәребез бер хәдисендә болай ди: "Аллаһтан куркыгыз вә балаларыгыз хакында гаделлектән аерылмагыз";

- ата-ана баланың яхшы дус табуына дикъкать итәр, чөнки начар кешеләр баланы юлдан яздырырга мөмкин;
- өйләнү яшенә җиткәч, баласын дөрес итеп өйләндерер.

### БАЛАЛАРНЫҢ АТА-АНАЛАРЫНА КАРАТА БУЛГАН ВАЗИФАЛАРЫ

Безнең дөньяга килеүбезгә ата-аналарыбыз сәбәп булган. Алар безне тәрбияләп үстергәннәр. Тормышларының иң кыйммәтле вакытларын безгә багышлаганнар, авырлыкларга да карамый безне яхшы кеше итәргә тырышканнар. Шуның өчен дә аларның бездә чиксез хаклары бар. Ата-ана хакын түләп бетерергә мөмкин түгел. Алар бездән канәгать вә рази булсалар, без балалык вазифаларыбызны үтәгән булып исәпләнербез.


Балалар ата-аналарына бер вакытта да ачуланып карамаслар, акырып-бакырып аларны рәнҗетмәсләр. Коръ-әндә Аллаһы Тәгалә дигәндәр ки: "...ата-анага өф тә ди-мә...".

- балалар ата-аналарына һәртөрле хөрмәт күрсәтеп, аларга итагатьле булырлар. Пәйгамбәребез бер хәдисендә болай дигән: "Ата-анага итәгать - Аллаһка итәгатьтер. Аларга каршы тору - Аллаһка каршы торудыр";
- балалар ата-аналары чакыру белән үк йөгереп килерләр, аларның йомышларын җиренә җиткереп үтәрләр, йомшак вә татлы тел белән җавап кайтарырлар;
- мохтаҗ хәлдәге ата-анага балалары һәр вакыт ярдәм итәрләр;
- кая булса да китәргә кирәк булганда рөхсәт сорарлар, ата-аналарына хәбәр бирерләр;
- ата-ана өйгә кергәндә, балалар аларны аягүрә каршы алырлар;
- вафат булган ата-аналарын балалар онытмаслар, һәрвакыт аларны догалар белән искә төшерерләр, каберләрен барып зиярәт итәрләр. Балаларның ата-аналарына карата булган вазифалары турында пәйгамбәребез ике хәдисендә шулай дигән: "Аллаһ яраткан иң сөекле гамәлләр, эшләр - вакытында укылган намаз вә ата-анага яхшылык кылудыр". "Җәннәт - әниләрнең аяклары астындадыр".

### ТУГАННАР ҺӘМ КАРДӘШЛӘРНЕҢ БЕР-БЕРЛӘРЕНӘ КАРАТА БУЛГАН ВАЗИФАЛАРЫ

Ата-анадан кала безгә якын булган кешеләр - туганнарыбыздыр. Үзебезне яраткан кебек без аларны да шулай ук яратырга тиешбез. Ата-ананың вафатыннан соң иң олы ул - ата, иң олы кыз - ана урыныннадыр. Яшьрәк туганнар абыйапаларны хөрмәт кылырлар. Алар да яшьрәк туганнарына ата-ана шәфкате күрсәтерләр;

- туганнар ата-анадан калган мал вә акчаны тигезлек белән бүлешерләр, мирас мәсьәләсендә бер-берләрен рәнҗетмәсләр. Туганнар арасында иң күп үпкәләшүләр бу мәсьәләгә караганда күрә, моңа аеруча дикъкать итәргә кирәк;
- туганнар һәм кардәшләр бер-берләре белән яхшы яшәрләр, кайгы вә шатлыкларын уртак итәрләр;
- туганнар, якын яшәсәләр, үз-ара йөрешерләр; аралары ерак булса хатлар вә телефоннар ярдәмендә элемтәдә торырлар. Туганнар арасындагы мондый мөнәсәбәтләргә Ислам динендә "сила-и рәхим" диелә. Пәйгамбәребезбер хәдисендә болай дигән: "Ризыгы мул, гомере озын булуын теләгән кеше кардәшләренең хәлен белсен, аларны зиярәт кылсын";
- бай кешеләр ярлы туган һәм кардәшләренә ярдәм итәрләр. Динебез буенча зәкать вә сәдака ярлыларга бирелер. Ләкин кардәшләр арасында ярлылар булса, аларга бирү саваплырактыр;
- туган һәм кардәшләр бербер сенә карата хата эшләсәләр, гафу ителерләр, үпкә тотмаслар, чөнки динебездә өч көннән артык сөйләшмичә тору дөрес саналмый.



## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Рабиғел әүүәл 2011 миләди йыл**
**1432 һижри йыл.**

| Рабиғел ахыр | Аҙна көндәре | Март, апрель | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сығa | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Йәкшәмбе | 6 | 6.27 | 7.57 | 13.30 | 17.29 | 18.59 | 20.29 |
| 2 | Дүшәмбе | 7 | 6.24 | 7.54 | 13.30 | 17.31 | 19.01 | 20.31 |
| 3 | Шишәмбе | 8 | 6.22 | 7.52 | 13.30 | 17.33 | 19.03 | 20.33 |
| 4 | Шаршамбы | 9 | 6.19 | 7.49 | 13.30 | 17.35 | 19.05 | 20.35 |
| 5 | Кесе йома | 10 | 6.17 | 7.47 | 13.30 | 17.37 | 19.07 | 20.37 |
| 6 | Йома | 11 | 6.14 | 7.44 | 13.30 | 17.39 | 19.09 | 20.39 |
| 7 | Шәмбе | 12 | 6.12 | 7.42 | 13.30 | 17.41 | 19.11 | 20.41 |
| 8 | Йәкшәмбе | 13 | 6.09 | 7.39 | 13.30 | 17.43 | 19.13 | 20.43 |
| 9 | Дүшәмбе | 14 | 6.07 | 7.37 | 13.30 | 17.45 | 19.15 | 20.45 |
| 10 | Шишәмбе | 15 | 6.04 | 7.34 | 13.30 | 17.47 | 19.17 | 20.47 |
| 11 | Шаршамбы | 16 | 6.02 | 7.32 | 13.30 | 17.49 | 19.19 | 20.49 |
| 12 | Кесе йома | 17 | 5.59 | 7.29 | 13.30 | 17.51 | 19.21 | 20.51 |
| 13 | Йома | 18 | 5.57 | 7.27 | 13.30 | 17.53 | 19.23 | 20.53 |
| 14 | Шәмбе | 19 | 5.54 | 7.24 | 13.30 | 17.55 | 19.25 | 20.55 |
| 15 | Йәкшәмбе | 20 | 5.52 | 7.22 | 13.30 | 17.56 | 19.26 | 20.56 |
| 16 | Дүшәмбе | 21 | 5.49 | 7.19 | 13.30 | 17.58 | 19.28 | 20.58 |
| 17 | Шишәмбе | 22 | 5.47 | 7.17 | 13.30 | 18.00 | 19.30 | 21.00 |
| 18 | Шаршамбы | 23 | 5.44 | 7.14 | 13.30 | 18.02 | 19.32 | 21.02 |
| 19 | Кесе йома | 24 | 5.41 | 7.11 | 13.30 | 18.04 | 19.34 | 21.04 |
| 20 | Йома | 25 | 5.39 | 7.09 | 13.30 | 18.06 | 19.36 | 21.06 |
| 21 | Шәмбе | 26 | 5.36 | 7.06 | 13.30 | 18.08 | 19.38 | 21.08 |
| | | | | Йәйге ваҡыт | | | | |
| 22 | Йәкшәмбе | 27 | 6.34 | 8.04 | 13.30 | 19.10 | 20.40 | 22.10 |
| 23 | Дүшәмбе | 27 | 6.31 | 8.01 | 13.30 | 19.12 | 20.42 | 22.12 |
| 24 | Шишәмбе | 29 | 6.29 | 7.59 | 13.30 | 19.14 | 20.44 | 22.14 |
| 25 | Шаршамбы | 30 | 6.26 | 7.56 | 13.30 | 19.16 | 20.46 | 22.16 |
| 26 | Кесе йома | 31 | 6.24 | 7.54 | 13.30 | 19.18 | 20.48 | 22.18 |
| 27 | Йома | 1 | 6.21 | 7.51 | 13.30 | 19.20 | 20.50 | 22.20 |
| 28 | Шәмбе | 2 | 6.19 | 7.49 | 13.30 | 19.22 | 20.52 | 22.22 |
| 29 | Йәкшәмбе | 3 | 6.16 | 7.46 | 13.30 | 19.23 | 20.53 | 22.23 |

# ҖОМГА КӨН

Динебездәге иң изге көннәрдән берсе - җомга көндер. Пәйгамбәребезнең хәдисе буенча, җомга көн гает вә Ашура көннәреннән изгерәктер. Җомга көн - мөселманнарның бәйрәмедер. Бу көнне өйлә сәгатендә җәмәгать белән укыла торган җомга намазы бар. Иң аз дигәндә атнага бер мәртәбә мәчеткә барып бу намазны уку, хөтбә тыңлау мөселманнарга фарыздыр. Сәбәпсез җомга намазын калдыру - зур гөнаһтыр.

Җомга көнне балаларга бүләкләр алып, аларны шатландыру, ярлыларга ярдәм бирү, каберләрне зиярәт итү, госел тәһарәте алып, яңа вә ару киемнәр киеп мәчеткә бару, кардәшләр белән күрешү - дини гадәтләребездәндер.

Җомга көн кайбер мөселман мәмләкәтләрдә ял көне итеп игълан ителгән. Моның максаты - кешеләр, җомга намазына катнашып, бу изге көннең үз өлешләрен алсыннар димәктер. ләкин җомга көн, яһүдиләрдәге шимбә көн вә христианнардагы якшәмбе кебек, эштән калу көне түгел. Җомга көнне, җомга намазы сәгатеннән башка вакытларда эш эшләргә ярый. Пәйгамбәребезнең хәдисе буенча, җомга көнендә кылынган догаларны Аллаһы Тәгалә кабул итә торган бер сәгать бар. Ләкин бу сәгатьнең кайсы вакытка туры килеүен бер кем дә белми. Моның максаты - мөселманнарны мөмкин кадәр көн буе гыйбадәт хәлендә тоту, яхшы вә саваплы эшләргә өндәүдер.

Адәм пәйгамбәр җомга көнне яратылган. Шуның өчен адәм баласы бар ителгән бу көн изге көн дип кабул ителгән. Бу көнне бер-березне хөрмәтләү, гыйбадәт үә догалар кылып, Аллаһка рәхмәтебезне белдерү һәр мөселманның вазифаларынанндыр.